КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 26 сентябрь г.Казань № 1037

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында» 2021 ел, 26 ноябрь, 1136 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында» 2021 ел, 26 ноябрь, 1136 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 28 февраль, 172 нче; 2022 ел, 9 март, 213 нче; 2022 ел, 16 апрель, 360 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 9 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«шартнамә (дәүләт контракты) суммасының 50 процентыннан 90 процентына кадәр, әмма иң күбе бюджет йөкләмәләре лимитлары күләмендә – Идел елгасына куркыныч тудыра торган, тупланган экологик зыян объектларын бетерү (рекультивацияләү) чараларын тормышка ашыруга шартнамәләр (дәүләт контрактлары) буенча (әгәр шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган, максатчан билгеләнеше булган бюджетара трансфертлар әлеге объектларны финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып торса), «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына федераль бюджет турында» 2021 елның 6 декабрендәге 390-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясындагы 3 өлеше нигезендә финанслар белән тәэмин итү акчасы казначылык контролендә тотылырга тиешле шартнамәләр (дәүләт контрактлары) буенча;».

2. Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алучылар «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 112 статьясындагы $65^1$ өлеше нигезендә яклар килешүе буенча бу карар үз көченә кергәнгә кадәр төзелгән шартнамәләргә (дәүләт контрактларына) аларда каралган аванс түләүләре күләмнәрен, «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 96 статьясындагы 6 өлеше нигезендә билгеләнә торган шартнамә (дәүләт контракты) үтәлешен тәэмин итү күләмен саклап, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында» 2021 ел, 26 ноябрь, 1136 нчы карарының 9 пунктындагы җиденче абзацында билгеләнгән күләмнәренә кадәр арттыру өлешендә үзгәреш кертергә хокуклы.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин